Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Красный Ключ авыл җирлеге составына керүче Красный Ключ торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2021 елның 25 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Красный Ключ авыл җирлегенең Красный Ключ торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Красный Ключ авыл җирлеге Красный Ключ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 1 нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге (уку йортына йөреп уку) уку студентларыннан тыш; 2 нче төркем инвалидларына һәм 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерларга, күп балалы гаиләләргә 50% түләү белән, 300 сум күләмендә 2022 елда үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны Красный Ключ поселогындагы «Сугышчылар» Мемориалын ремонтлауга (материаллар, кече архитектура формалары сатып алу, килешү, контракт буенча эшләр өчен түләү) юнәлдерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Красный Ключ авыл җирлеге башлыгы И.К.Зәйнетдинов